ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨСТӘМӘ БЕЛЕМ БИРҮ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ “МӘКТӘПТӘН ТЫШ ЭШЛӘР ҮЗӘГЕ”

Педагогик киңәшмә утырышында кабул ителде:
Беркетмә № 3
“06” 04 2020 ел

“Раслыйм”
“МТЭҮ” ӨБ МБУ директоры
Латипов Р.К.
Боерык № 11
“16” апрель 2020 ел

**РУХИ- ӘХЛАКЫЙ ТӘРБИЯ БУЕНЧА**

**ГОМУМИ БЕЛЕМ ҺӘМ ГОМУМИ ҮСЕШ БИРҮНЕҢ**

**дистанцион белем бирү технологияләре белән**

# “МИРАС” ӨСТӘМӘ ПРОГРАММАСЫ

*Юнәлеше: иҗтимагый-педагогик*

*Укучыларның яше: 10-15 яшь*

*Тормышка ашыру вакыты: апрель-май*

Автор-төзүче: Ахметзянова Р.К.
Мифтахова Г.И.
Закирова Г.С.

2020

# I. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП ХАРАКТЕРИСТИКАЛАРЫ КОМПЛЕКСЫ

## 1.1. БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫНЫҢ МӘГЪЛҮМАТ КАРТАСЫ

| | | |
|---|---|---|
| **1.** | **Белем бирү оешмасы** | Балтач муниципаль районы “МТЭҮ” МБУ |
| **2.** | **Программаның тулы исеме** | рухи- әхлакый тәрбия буенча гомуми белем һәм гомуми үсеш бирүнең дистанцион белем бирү технологияләре белән “Мирас” өстәмә программасы |
| **3.** | **Программа юнәлеше** | иҗтимагый-педагогик |
| **4.** | **Төзүчеләр турында мәгълүмат** | Ахметзянова Р.К.,<br>Мифтахова Г.И.,<br>Закирова Г.С.,<br>өстәмә белем бирү педагоглары |
| **5.** | **Программа турында мәгълүмат** | |
| 5.1 | Тормышка ашыру вакыты | Апрель - май |
| 5.2 | Укучыларның яше | 10-15 яшь |
| 5.3 | Программа характеристикасы:<br>-программаның тибы:<br>-программаның төре:<br>-программаны проектлау принцибы:<br>-укыту процессының эчтәлеген оештыру формасы: | <br>-өстәмә белем бирү программасы<br>-гомуми үсеш бирү программасы<br>-төрле дәрәҗәдәге<br><br>-модульле |
| 5.4 | Программаның максаты | Халкыбызның этик һәм дини мәдәниятен өйрәнү |
| 5.5 | Белем бирү модуле | Башлангыч дәрәҗә:<br>-әдәп-әхлак нигезләрен өйрәтү<br>Башлангыч дәрәҗә:<br>-өйрәнелгән кагыйдәләр нигезендә күркәм холык булдыру<br>Урта дәрәҗә:<br>-халкыңның тәрбия, уку -язу мирасын өйрәнү,гыйлемгә мәхәббәт тәрбияләү |
| **6** | **Белем бирү формалары һәм методлары** | төркем белән һәм аерым (индивидуаль),әңгәмә,лекция,мастер-класслар |
| **7** | **Нәтиҗәлелек мониторингы формалары** | иҗади отчёт, уен,конкурс |
| **8** | **Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге** | Зыялы шәхес сыйфатларын ачыклау һәм үтәргә тырышу |
| **9** | **Программаны раслау һәм төзәтмәләр кертү вакыты** | 2019 |
| **10** | **Рецензентлар** | |

## 1.2. АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Бу программа  иҗтимагый- педагогик юнәлештә белем һәм тәрбия бирүне үз эченә алган һәм Россия хөкүмәтенең хокукый норматив документларына таянып төзелгән.Болар:

“Бала хокуклары турында конвенция”

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының№14-53-281 ин/14-04 саны астында 4.06.99 дата белән җибәрелгән хаты.

Россия Федерациясенең мәгариф һәм фән министрлыгының белем бирү турында федераль законы. 29 декабрь 2012 ел.№273

2013-2020 елларга “Мәгариф үсеше” РФ Дәүләт программасы

“Балаларга өстәмә белем бирү программаларына якынча таләпләр” №06-1844, 11.12.2006

Белем бирү эшчәнлеген тормышка ашыру өчен өстәмә белем бирү программаларын оештыру тәртибен раслау” Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгының 29.08.2013 елгы №1008нче приказы.

СанПиН санитар-эпидемиологик кагыйдәләре һәм нормативлары 2.4.4.3172-14 (20 август 2014 ел №33660 белән теркәлгән)

Балаларга өстәмә белем бирү концепциясе.4 сентябрь 2014ел

Өстәмә белем бирү программаларын проектлаштыру буенча методик рекомендацияләр.Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгының 18ноябрь 2015елгы хаты №09-3242

Өстәмә белем бирү буенча рекомендацияләр.Буйлова Л.Н. Мәскәү ГАОУ ВО”Московский институт открытого образования” 2015.

Өстәмә белем программаларын тормышка ашыру өчен методик рекомендацияләр. Төзүчеләр: М.М.Шалашова,Д.А.Махотин. Мәскәү,ГБОУ ВО МПГУ ,2016

Россия Федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгы хаты “Мәгълүмати юнәлешләр турында” 18.11.2015 №09-3242

Өстәмә белем бирүдә төрле программалар төзү буенча методик рекомендацияләр. Мәскәү,ГАОУ ВО”МГПУ”, АНО ДПО “Открытое образование”,2016.

Өстәмә белем бирү программаларын заманча проектлаштыру буенча методик рекомендацияләр.ГБУ ДО “Тәрбия эшләре буенча Республика үзәге” 2017.

Учреждениенең уставы

Соңгы елларда  җәмгыятебездә шәфкатьсезлек, миһербансызлык арта бара. Әдәпсезлекнең күзне ертып, җанны кыйный торган чагылышларыннан булган ямьсез сөйләм, матурлыкны күрә белмәү, табигатьне пычрату, өлкәннәргә хөрмәт булмау, яшьләр арасында үз юлларын сайлый белмичә , дөньякүләм танылган диннәрнең асылын аңламыйча, мәктәпне бетереп гаиләдән аерылу белән җәмгыятьтә төрле шикле агымнарга ияреп китү кебек күренешләр белән һәрдаим очрашып торабыз. Җәмгыятебезнең

әхлаксезлегендә мәктәп гаиләне, гаилә мәктәпне гаепли. Чынлыкта,дәресләрнең төп максаты белем бирү булганлыктан, дәрестән тыш чаралар әхлак тәрбиясе бирү максатын үз эченә алып, әдәплелек тәрбияләү белән күбрәк мәшгуль булырга кирәктер, гомумән, халкыбызның дини мирасын өйрәнү заруридыр дигән фикер һәм эти-әниләрнең соравы, дөньякүләм танылган диннәр тәгълиматына таянып, әхлак тәрбиясе бирү программасы булдыруга этәргеч булды.

**Программаның максаты:** Халкыбызның этик һәм дини мәдәниятен өйрәнү**.**

**Программаның бурычлары:**Рухи байлык, җан тынычлыгының нигезе матур әхлак икәнлегеен танырга өйрәтү дистанцион укыту вакытында. Матур әхлакнең матур гадәтләр җыелмасы икәнлегеен төшендерү. Дини тәгълиматны аңларга ярдәм итү.

Программа,эти-әниләре ислам дине тәгълиматын өйрәтүгә риза булган, 10 яшьтән алып 15 яшькә кадәр булган мәктәп балалары өчен төзелде.

Дәресләр режимы һәм формалары: 2.2.2/2.4.1340-03 номерлы СанПиН таләпләренә туры китереп, онлайн режимда дистанцион дәресләр 20 мин. атнага 4әр сәгать.